
# Г.Ибраһимов әсәрләрендә парлы сүзләрнең стилистик кулланылышы

Г.Ибраһимов – татар әдәбиятында гына түгел,татар тел белемендә, татар иҗтимагый фикер үсешендә җуелмас эз калдырган олуг шәхесләребезнең берсе.



ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ
(1887—1938)

М.Хасанов күренекле татар әдәбияты классигы Г.Ибраһимовны “энциклопедист”, дип атый һәм бөек әдипләр Гете,А.С.Пушкин, Л. Н.Толстой, Т.Шевченко,М.Горький, Райнислар белән бер рәткә куеп карый. Чылап та, Г.Ибраһимов – энциклопедик галим.

# Фәнни эшнең максаты.

Г.Ибраһимов әсәрләрендә парлы сүзләрне барлап,


аларның әдәби әсәрдәге ролен ачыклау.


Максаттан чыгып түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

- парлы сүзләр турында төшенчәне табып теркәү;
- нинди функцияне үтәвен аңлату;
- әдип әсәрләренә анализ ясау.

# **Фәнни эшнең өйрәнү объекты.**

Фәнни эшнең өйрәнү объекты итеп Г.Ибраһимов әсәрләре алынды.






- Парлы сүзләрнең кулланыш сферасы бик киң, алар матур әдәбиятта да, публицистикада да, хат-истәлекләрдә дә, фән телендә дә,сөйләү телендә дә шактый күп очрый.
- Парлы сүзләрнең ясалышы шулай ук синтаксик яки сүзләр кушу ысулы белән сүз ясалышына карый.
- Парлы сүзләр үзара т е з ү л е б ә й л ә н е ш т ә г е сүзләр кушылу юлы белән ясала (ипи-тоз, сөт-катык, өс-баш, ара-тирә, аклы-каралы).

*Тумашева фикеренчә, парлы сүзләр, гадәттә, очраклы сүзләрнең парлашуыннан түгел, ә үзара нинди дә булса лексик-мәгънәви бәйләнештә торган сүзләр кушылудан барлыкка килә. Бу үзара якын яки синонимик мәгънәле сүзләр, капма-каршы (антонимик) мәгънәле сүзләр парлашуы, парлы сүзләр нинди дә булса билге буенча охшату, гомумиләштерү (ассоциация) нигезендә парлашкан сүзләрдән дә ясалырга мөмкин.*

# Яшь йөрәкләр.

*Мәрьям,тәмам бер* ***кыз-каһарман*** *кыяфәте алып, дусты Зыяга хат язды.*

*Бу очракта кызның тойгысы көчле булып, искелеккә каршы чыгуын күрсәтә. Чөнки ул чорда шәригать кануннары буенча кызларга хат язу тыелган булган. Бу аның ул таләпләргә каршы чыгарлык батырлык,*

*каһарманлык күрсәтүен чагылдыра.*

# Яз башы.

*Камышка якынайган саен, аның хакында сөйләгән куркынычлар, аякланып, каршыма чыгар кеби тоелу көчәя бара, күзем **әлҗе-мөлҗе** килеп, зиһенем ят, куркыныч бер гамәлгә кереп югала тора иде.*

Бу очракта язучы **әлҗе-мөлҗе** парлы сүзен җөмлә тагын да образлырак , бизәклерәк чыксын, малайның куркуын юмор белән бирү өчен кулланган.

# Адәмнәр

**Аннан-моннан** *капкаладым да, тагы әллә нинди авыр уйлар белән тышка чыгып, ындырга көлтә бушатырга киттем.*

**аннан-моннан** парлы сүзе урынына **тиз генә** яисә **аз гына** сүзләрен кулланса, бу фикер уңышлы чыкмас иде, чөнки **аз гына**-ул тирән уйларга чумуны, ә **тиз генә** ашыгуны белдерер иде. **Аннан-моннан** парлы сүзе аша кешедә ашау кайгысы юк, башка уйлар бик борчуын һәм эшне тизрәк эшләргә кирәклеген дә белдереп килә.

# Нәтиҗә

- парлы сүзләрнең кулланыш сферасы бик киң,
- парлы сүзләр Г. Ибраһимов иҗатында да, автор хикәяләвендә дә герой–персонажлар сөйләмендә дә уңышлы кулланыла. Геройларның портретын, эчке дөньясын, рухи халәтен тасвирлауга зур ярдәм күрсәтәләр,
- Г. Ибраһимов парлы сүзләрне уңышлы, оста кулλануы белән әсәрне тагын да эчтәлеклерәк итүгә ирешкән.

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!